ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

**№** ***62*** **от «** ***20*** **»** ***сентября*** **20** ***17*** **г.**

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы К А Р А Р Б И Р Д Е:

1. Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга::

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән кала, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу:

Мамадыш шәһәре территориясендә видеокүзәтү урнаштыру;

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны да кертеп):

Мамадыш шәһәре территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү;

Мамадыш шәһәре территориясендә ике телдә урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр әзерләү һәм урнаштыру;

-Мамадыш шәһәре территориясендә балалар уен мәйданчыкларын төзү һәм реконструкцияләү;

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу:

Мамадыш шәһәре территориясендә каты көнкүреш калдыкларын җыю урыннарын төзекләндерү;

Халыкның күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә:

Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерүне оештыру.

« ӘЙЕ »                                        « ЮК »

3.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе                                        Р.М. Гарипов